КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2026 ел, 8 май г.Казань № б-925

1. Бу боерыкка теркәлгән 2021 – 2030 елларга Россия казакларына карата Россия Федерациясе дәүләт сәясәте стратегиясен Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру буенча 2027 – 2030 елларга чаралар планын расларга.

2. Республика башкарма хакимият органнарына аның үтәлеше турындагы мәгълүматны ярты елга бер тапкыр, 10 июньгә кадәр һәм 10 декабрьгә кадәр, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кертергә, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына һәм әлеге планны гамәлгә ашыруда катнашучы оешмаларга – кертүне тәкъдим итәргә.

3. Бу боерык 2027 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. 2027 елның 1 гыйнварыннан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 17 октябрь, б-2265 нче боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

5. Бу боерыкның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин